МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.02.2016_ г. Казань № _под-257/16

**Татарстан республикасы мәгариф һәм фән министрлыгында татарстан республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар, шулай ук сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен (фәнни исемнәрдән тыш), бүләкләрен алу тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясенең дәүләт гражданхезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы аедераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Россия Федерациясенең аерым дәүләти вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәтенең аерым вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен алу тәртибе турында нигезләмәне раслау турында» 2015 елның 10 октябрендәге 506 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасына билгеләү һәм вазыйфадан азат итү Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан хәл ителә торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен алу тәртибе турында нигезләмәне раслау турында» 2016 елның 12 гыйнварындагы УП-5 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар, шулай ук сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен (фәнни исемнәрдән тыш), бүләкләрен алу тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәүгә алынганнан соң, кадрлар сәясәте бүлегенә (Т.А.Иванова) бу боерык белән Министрлыкның барлык структур бүлекчәләре хезмәткәрләрен таныштырырга.

7. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр Э.Н.ФӘТТАХОВ

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 24 февралендәге под-257/16 номерлы боерыгы белән расланды

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАН ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ ТАРАФЫННАН ЧИТ ИЛ ДӘҮЛӘТЛӘРЕНЕҢ, ХАЛЫКАРА ОЕШМАЛАР, ШУЛАЙ УК СӘЯСИ ПАРТИЯЛӘР, БАШКА ИҖТИМАГЫЙ БЕРЛӘШМӘЛӘРНЕҢ ҺӘМ ДИНИ БЕРЛӘШМӘЛӘРНЕҢ МАКТАУЛЫ ҺӘМ МАХСУС ИСЕМНӘРЕН (ФӘННИ ИСЕМНӘРДӘН ТЫШ), БҮЛӘКЛӘРЕН АЛУ ТӘРТИБЕ**

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – граждан хезмәткәре, Министрлык) тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен (фәнни исемнәрдән тыш), бүләкләрен (алга таба – исемнәр, бүләкләр), граждан хезмәткәренең вазыйфаи бурычларына әлеге оешмалар һәм берләшмәләр белән хезмәттәшлек итү кергән очракта, алу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында эшләнде.

2. Граждан хезмәткәре исемнәр, бүләкләр алганда Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрыннан (алга таба – Министр) рөхсәт алырга тиеш.

3. Исем, бүләк алган яки чит ил дәүләте, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә, дини берләшмә тарафыннан исем яки бүләк бирелү турында хәбәр алган граждан хезмәткәре өч эш көне эчендә Министрлыкның кадрлар сәясәте бүлегенә (алга таба - кадрлар сәясәте бүлеге) Министр исеменә чит ил дәүләтенең, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә, дини берләшмәнең мактаулы яки махсус исемен (фәнни исемнәрдән тыш), бүләген алуга рөхсәт бирү турында бу Тәртипкә 1нче кушымта нигезендә төзелгән үтенечнамә (алга таба – үтенечнамә) тапшыра. Үтенечнамәне карап тикшерү вакыты 10 эш көне тәшкил итә.

4. Исемнән, бүләктән баш тарткан граждан хезмәткәре өч эш көне эчендә кадрлар сәясәте бүлегенә Министр исеменә чит ил дәүләтенең, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә, дини берләшмәнең мактаулы һәм махсус исемен (фәнни исемнәрдән тыш), бүләген алудан баш тарту турында бу Тәртипнең 2нче кушымтасында күрсәтелгән формада тутырылган язма хәбәр (алга таба – язма хәбәр) тапшыра.

5. Исем, бүләк алган граждан хезмәткәре үтенечнамәне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Министр тарафыннан карар кабул ителгәнче, исемгә документларның төп нөсхәләрен һәм бүләкне һәм аңа документларның төп нөсхәләрен, аларны алганнан соң өч эш көне эчендә, кадрлар сәясәте бүлегенә җаваплы саклауга тапшыра. Шул ук вакытта бу Тәртипкә нче3 кушымта нигезендәге форма буенча кабул итеп алу-тапшыру акты төзелә.

6. Граждан хезмәткәре хезмәт командировкасы вакытында исем, бүләк алганда яки алардан баш тарткан очракта, үтенечнамә яки язма хәбәр тапшыру вакыты граждан хезмәткәренең хезмәт командировкасыннан кайткан көннән башлап исәпләнелә.

7. Граждан хезмәткәре, үзенә бәйсез сәбәп аркасында, үтенечнамәне яки язма

хәбәрне, исемгә документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа документларның төп нөсхәләрен бу Тәртипнең 3-5 пунктларында күрсәтелгән вакытта тапшыра алмаган очракта, үтенечнамәне яки язма хәбәрне, исемгә документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа документларның төп нөсхәләрен мондый сәбәп юкка чыгарылганнан соң килгән эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырырга тиеш.

8. Үтенечнамәне (язма хәбәрне) теркәү кадрлар сәясәте бүлеге тарафыннан, кабул итеп алынган көнне бу Тәртипкә 4нче кушымта нигезендә төзелгән теркәү журналында башкарыла. Кадрлар сәясәте бүлеге ике эш көне эчендә теркәлгән үтенечнамәне (язма хәбәрне) Министрга карап тикшерүгә җибәрә.

9. Кадрлар сәясәте бүлеге ике эш көне эчендә граждан хезмәткәренә үтенечнамәне (язма хәбәрне) карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Министр кабул иткән карар турында хәбәр итә һәм аңа, Министр резолюциясе белән, үтенечнамәнең (язма хәбәрнең) кадрлар сәясәте бүлеге мөһере белән расланган күчермәсен, имза салдырып, тапшыра. Министр резолюциясе белән үтенечнамәнең (язма хәбәр) төп нөсхәсе граждан хезмәткәренең шәхси эшенә куела.

10. Кадрлар сәясәте бүлеге, Министр бу Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән граждан хезмәткәре үтенечнамәсен канәгатьләндергән очракта, 10 эш көне эчендә граждан хезмәткәренә исемгә документларны төп нөсхәләрен, бүләк һәм аңа документларның төп нөсхәләрен тапшыра. Шул ук вакытта бу Нигезләмәнең 3нче кушымтасы нигезендә кабул итеп алу-тапшыру акты төзелә.

11. Кадрлар сәясәте бүлеге, Министр бу Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән граждан хезмәткәре үтенечнамәсен канәгатьләндерүдән баш тарткан очракта, 10 эш көне эчендә исемгә документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа документларның төп нөсхәләрен чит ил дәүләтенең, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә, дини берләшмәнең тиешле органына җибәрә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар, шулай ук сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен (фәнни исемнәрдән тыш), бүләкләрен алу тәртибенә 1нче кушымта

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрына
___________________________________
_______________________________дән
___________________________________
(Ф.И.О., били торган вазыйфасы)

Чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар, шулай ук сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен (фәнни исемнәрдән тыш), бүләкләрен алырга рөхсәт бирү турында
ҮТЕНЕЧНАМӘ

Миңа кабул итүгә рөхсәт бирүегезне сорыйм __________________________________________________

________________________________________________________________________________
(мактаулы яки махсус исем, бүләк атамасы)

________________________________________________________________________________
(нинди хезмәтләр өчен һәм кем тарафыннан бирелгән, нинди хезмәтләр өчен бүләкләнгән һәм кем тарафыннан)

________________________________________________________________________________
(мактаулы яки махсус исемгә, бүләккә документлар тапшыру датасы һәм урыны)

Мактаулы яки махсус исемгә документлар, бүләк һәм аңа документлар
(кирәклесенең астына сызарга)

________________________________________________________________________________
(мактаулы яки махсус исем, бүләк атамасы)

________________________________________________________________________________
(мактаулы яки махсус исемгә, бүләккә документлар атамасы)

________________________________________________________________________________
кабул итеп алу-тапшыру акты буенча тапшырылган №___ «____»________ 20___ел

кадрлар сәясәте бүлегенә.
(бүлек атамасы)

"__" ___________ 20__ ел. _________________ _____________________________
(имза) (тулы имза)

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар, шулай ук сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен (фәнни исемнәрдән тыш), бүләкләрен алу тәртибенә 2нче кушымта

Татарстан Республикасы
мәгариф һәм фән министрына

____________________________________
_________________________________дән
____________________________________
____________________________________
(Ф.И.О., били торган вазыйфасы)

Чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар, шулай ук сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен (фәнни исемнәрдән тыш), бүләкләрен алудан баш тарту турында язма хәбәр

… алудан баш тарту турында карар кабул итүемне җиткерәм

__________________________________________________________________________
(мактаулы яки махсус исем, бүләк атамасы)

__________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________
(нинди хезмәтләр өчен һәм кем тарафыннан бирелгән, нинди хезмәтләр өчен бүләкләнгән һәм кем тарафыннан)

"__" __________ 20__ ел ________________ ___________________________
(имза) (тулы имза)

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар, шулай ук сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен (фәнни исемнәрдән тыш), бүләкләрен алу тәртибенә 3нче кушымта

Кабул итеп алу-тапшыру акты

"__" __________ 20__ ел N _______

Без, түбәндә кул куючылар, түбәндәге турында акт төзедек

___________________________________________________________________________

(Ф.И.А., вазыйфасы)тапшырды/кабул итте (кирәклесенең астына сызарга),

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының кадрлар сәясәте бүлегенә

___________________________________________________________________________

(Ф.И.А., вазыйфасы) түбәндәгеләрне кабул итте/тапшырды (кирәклесенең астына сызарга):

| N п/п | Атамасы | Саны (данә) | Тасвирламасы |
| --- | --- | --- | --- |
| | | | |
| | | | |

Тапшырды Кабул итте

___________________________ ____________________________

(имзасы) (тулы имзасы) (имзасы) (тулы имзасы)

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләти
граждан хезмәткәрләре тарафыннан
чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар,
шулай ук сәяси партияләр,
башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм
дини берләшмәләрнең мактаулы
һәм махсус исемнәрен (фәнни исемнәрдән
тыш),
бүләкләрен алу тәртибенә 4нче кушымта

Үтенечнамәләрнең (язма хәбәрләр) исәбен алып бару өчен
ЖУРНАЛ

| N | Үтенечнамә (язма хәбәр) тапшырган граждан хезмәткәренең Ф.И.О. | Үтенечнамә (язма хәбәр) тапшырган граждан хезмәткәренең вазыйфасы | Үтенечнамәнең (язма хәбәр) алыну датасы | Бүләк, исем атамасы | Кабул итү-тапшыру акты (булганда) реквизитлары | Үтенечнамәне (язма хәбәр) кабул итеп алган затның имзасы, Ф.И.А. | Үтенечнамә (язма хәбәр) тапшырган затның имзасы, Ф.И.А. | Ми н ка тур мә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | |